**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
(V чакырылыш)

V чакырылышның чираттан тыш
утырышы

**КАРАРЫ**

«24» декабрь 2025 ел № 23 Урыссу ш.т.б.

2026 елга Ютазы муниципаль
районы муниципаль мөлкәтен
хосусыйлаштыруның фаразлау
планын (программасын) раслау турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 21.12.2001 ел, № 178-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2008 елның 30 маендагы 115 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында"гы нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районының күчемсез муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның 2026 елга кушымтада бирелә торган фаразлау планын (программасын) расларга.

2. Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2026 елга «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеген хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә

http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Законлылык, регламент һәм җирлекләр советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2025 елның 24 декабрендәге «23» карарына кушымта

2026 елга Ютазы муниципаль районының күчемсез муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

I бүлек. 2026 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары

2025 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) (алга таба текст буенча – Хосусыйлаштыруның фаразлау планы) "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 22.07.2008 ел, № 159-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2008 елның 30 маендагы 115 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында» гы нигезләмә нигезендә эшләнде.

Муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең базар икътисады шартларында төзелә торган системасының бер өлеше буларак 2025 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары булып «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру исәбенә муниципаль милек структурасын оптимальләштерү, шулай ук «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен гамәлгә ашыру тора.

2026 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан район бюджетына салым булмаган керемнәр керүне тәэмин итү;

- бюджетның керем өлешен арттыру;
- мөлкәтне карап тотуга район бюджетыннан чыгымнарны кыскарту.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге икътисадындагы структур үзгәрешләрне хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә түбәндәге сәбәпләр аркасында көтелми:

- хосусыйлаштыруга тәкъдим ителгән торак булмаган биналарда милекчесе үзгәргәндә муниципаль берәмлектәге икътисадый хәлгә сизелерлек йогынты ясарга сәләтле производство урнаштырылмый;

Мөлкәтне сату хисабына район бюджетына якынча 3000 мең сум алу планлаштырыла.

Хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) нигезендә сатылырга планлаштырыла торган объектның якынча бәясе базар бәясен уздырганнан соң төгәлләштерелергә тиеш.

Хосусыйлаштырылырга тиешле объектның фараз бәясе якынча базар конъюктурасыннан чыгып исәпләнгән.

2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган мөлкәт исемлегенә, муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып, өстәлергә мөмкин.

## II бүлек. Хосусыйлаштыру 2026 елда планлаштырылган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәте

| т/б | Исеме | Хосусыйлаштыру ысулы | Гамәлгә ашыруның күздә тотылган вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Автотранспорт чаралары - 5 берәмлек | ачык аукцион | 1-2 квартал |
| 2 | Су җылыту казаннары RS-A500 моделе - 3 берәмлек | ачык аукцион | 1 квартал |